ГЛАВА НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.37 А, с. Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБӘН УШМЫ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Советлар урамы, 37А йорт, Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление

“27” октябрь 2020 г. | № 4

**Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Түбән Ушмы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушмы авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-44 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Түбән Ушмы авылы китапханә мөдире Галимуллина Айсылу Салимжановнаны Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы авылы торак пунктында 2020 елның 15 ноябрендэ гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.
3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгы: Р.М. Ганиев